



Чаян

ISSN 0136-7110

САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ * ИЮЛЬ * 2016 * КАЗАН 13



Сергей ТЮНИН

Бу саннан алып
“Чаян” айга бер
тапкыр чыга
башлаячак.
Ләкин ике тапкыр
калынрак!

АННАН-МОННАН
ИНФОРМ
СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Рәсәй, Төрек ягының үтенече буенча, Төркиягә чикләнмәгән санда туристлар контингенты кертәчәк.
- Сөйләшеп килешү теориясе кулланышка алынды: Британия Европа союзыннан чыкты, бу маневр, Рәсәйлеләрнең ЖКХ тарифлары күтә-релүеннән игътибарларын читкә юнәлтү өчен эшләнде.
- Оборона министрлыгы карары нигезендә, бер төркем Рәсәй футбол җанатарларына чираттан тыш хәрби исемнәр бирелде.
- Төрек отельләре хуҗаларына, бәреп төшергән Рәсәй самолеты өчен, ашыгыч рәвештә компенсация акчасы җыю кирәклеге игълан ителгән.
- Рәсәйдә тагын да сыйфатлырак саклану дәрәҗәсендәге банкнотлар әйләнешкә кертелгән. Элеккеге купюраларның чәч сыман тукымасы сынучан, коры һәм чыдамсыз иде. Ә хәзер ул пөхтә һәм үзенә җәлеп итеп тора.
- Лондондагы аукционда, рекорд бәядән, Гагаринның ботинка бавын, Хрущевның башмагын, Ленинның кепкасын һәм Ельцинның кашыкларын сатканнар.
- Безнең җыелма команда җиңелгәннән соң, сәбәпнең, гомумән, Виктор Гусевта түгеллеге ачыкланган.
- Чукоткадагы чумда эшләүчеләр үзләренең профсоюзларын оештырганнар.
- Булачак Олимпиадада чегәннәр аерым команда булып чыгыш ясаячаклар. Алар атларда һәм боҗрада кунегүләр ясаячак.
- Автомобильчеләрнең үтенече буенча, машиналарын җайлап куя белмәүче хатын-кызлар өчен аерым парковкалар ачылачак.
- Хокук яклаучылар, "үлем сәбәбен" күрсәткән графада, дәвалаучы табибның исеме күрсәтелүен таләп итәләр.
- Әби, суыткычын өйгә кертү өчен, полиция чакырткан.

ШОМБАЙ
болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Футбол буенча Европа чемпионаты тәмамланды инде, ә безнең җыелма команда турында шау-шу һаман тынмый. Уйлап куям: мондый хурлыкка калмас өчен нәрсә эшләргә булыр иде икән?


Т. ЙОСЫПОВ,
футбол җанатары

минзәлә

– Безнең команданың шансы бар иде, – диде Шомбай ага. **– Инглизләрнең ки-рәген биргәч тә, дисквалификация буенча, кешечә китәргә тәкъдим ителде бит. Риза булмадылар, футбол уйнарга калдылар...**



Максим СМАГИН





Никита Белых турында бернинди начар сүз әйтә алмыйм... Мин мәчет өчен койма ясавын үтендем – әнә, хәзер ясыйлар... Дөрес, өч ел буе үгетлисе булды, тик ул начар кеше түгел... Ришвәтче, диләр. Алар арасында кем ришвәтче түгел соң? Кемдер эләгә, кемдер – юк. Ала торган булмасаң, өстә сине тотмыйлар да...

Зөфәр ГАЛИУЛЛИН,
Киров өлкәсе мөфтие

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Кеше берүзе генә сөйләгәндә һәрвакыт хаклы.

Әгәр дә сез телевизор карыйсыз икән, кичке яңалыклардан башка бөтен тапшыруларда шәп егетләр начарларын һәрвакыт җиңеп чыгуына игътибар иткәнсездер.

Машина йөртә башлау белән мин юл аша саграк чыга башладым.

Ирләр тән ләззәте, хатыннар рухи мөнәсәбәт тели. Ләкин барыбер бер үк нәрсә белән шөгыльләнәләр.

Әгәр дә туганнарыгыз һәм дусларыгыз сезгә шалтыратмый икән, димәк, аларның эшләре шәп бара.


Черкиләр кайбер хатыннардан күпкә әйбәтрәк: чөнки кан эчкәч, алар безелдәүдән туктыйлар.

Чын хатын гомерендә бер агач кисәргә, йорт җимерергә һәм кыз үстерергә тиеш.

Яшәү, гомумән, сәламәт нәрсә түгел, чөнки бөтен яшәгән кеше кайчан да булса үлә.

(зыялылар мәҗлесендә язып алынды)

Ринат АБЗАЛОВ



Алдыйм дигән үзе алданыр

Әле күптән түгел генә иске «Жигули»ның «Мерседес»ка бәрелү очрагы йөремсәк мәзәккә әйләнеп, автомобиль хуҗасы өчен мәхшәргә әверелгән булыр иде. Хәлләр, автограждан җаваплылыгын мәҗбүри рәвештә иминиятләштерү турында закон кабул ителгәч кенә җиңеләйде. Машинада йөрү җиңел һәм күңелле нәрсәгә әверелде. Әлбәттә, бөтен кеше өчен түгел – мошенниклар барыбер тынмады.

Күптән түгел Бөтенроссия иминият берлеге һәр машина хуҗасын үзенең ОСАГО полисына җентекләбрәк карарга мәҗбүр итә торган саннар китерде. Ил буенча дүрт миллион ялган полис йөри икән! Республикада исә аларның һәр унынчысы ялган! Күп кенә законны ихтирам итәргә ияләнгән гражданнар нинди документ белән йөргәннәрен үзләре дә белми. Ялган «полис»ны, арзанлыгына кызыгып, «әрәмтамакларны туйдырасым килми әле», дип, белеп алганнары җитәрлек, әлбәттә: кәгазь бармы – бар, берәр ничек ярар әле!

Казанда элек иминиятләштерү системасында эшләгән Римма Гарифуллова берничә йөз кешене шулай итеп «төп башына» утырта. Шома ханым үзенең карьерасын шәһәрнең ЮХИДИ автотранспорт регистрацияләү бинасы янында куелган павильонында башлап җибәрә. Анда ул актив рәвештә ялган страховкалар белән сәүдә итә башлый. Эшләр шәп бара – аферисткага хәтта агентлар ялларга да туры килә. Бары тик быел гына Гарифуллова, ниһаять, тотыла: клиентларның берсе, авариягә эләккәч, иминиятләштерү компаниясенә ялган полис бирә. Ханымның бланкларны каян алуы һаман билгесез – авызына су капканмыни: эләккәннән бирле бер сүз әйтми.

Ә Чаллыда чын мәгънәсендә «иминиятләштерү фирмасының» өстенә чыкканнар. Яшерен бизнесны оештыручы Альберт Васильев һәм Динар Хәйруллин халыкны 2013 елдан бирле алдап килгәннәр. Алардан миллион сумнан артык суммага 167 кеше зыян күргән. «Бизнесмен»нарның «амбар»ларында төсле принтерда басылган 680 чиста ОСАГО бланкы табылган. Әйтергә кирәк: ялган бланкны чынынан аеру җиңел түгел. Мошенниклар бөтен таләпләргә дә җавап биргән бөлгенлеккә төшкән компанияләрнең бланкларын да кулланганнар.

Фальшивкалар проблемасы шундый киң таралу алды ки, автомобилистларның хокукларын яклаучылар президентка авария очрагында күрелгән зыянны каплау тәртибен үзгәртүдә булышлык күрсәтү үтенече белән мөрәҗәгать иттеләр. Ягъни, акча бирмичә, автомобильне турыдан-туры ремонтка илтергә. Тик бу тәкъдим автойөртүчеләр арасында ризасызлык тудырды. Ватылган машинасын һәркемнең дә таныш кешегә, йә ышанычлы кулларга бирәсе килә бит.

ЮХИДИга үзенең мәгълүматлар базасын ачып, «конкурентлар» белән көрәшкә Росссия иминиятләштерү берлеге дә килеп кушылды. «Дөрес иминиятләштерелмәгән» гражданнарны тоту җиңеләйде – моның өчен компьютерга полис номерын кертү дә җитә. Җаваплылык та көчәйтелде – хәзер ялган документ файдаланган өчен статьяга эләгү мөмкин.

Тиешле чаралар кертелүгә карамастан, бу кәсеп белән шөгыльләнүчеләр саны кимеми. Газеталарда һәм Интернетта реклама чыгу дәвам итә, телефоннан кызыктыргыч «смс»лар килә тора, ЮХИДИ бинасы янында шикле «агент»лар йөри. Һәм элеккечә акча экономияләргә теләүчеләр дә табылып тора. Ә бит моннан янга калган акчадан күпкә кыйммәтрәк төшкән очракка да ерак түгел.

Людмила САФИУЛЛИНА




Александр ЛЕВИТИН

Василий АЛЕКСАНДРОВ



Александр АЛЁШИН





• • •

Безгә рубльнең курсы йөзә торган була дип ышандырдылар. Ә менә әле аның чумып-чумып та алганын әйтергә онытканнар...

• • •

Илья Муромец:

— Змей Горыныч, нишләп әле син хәзер бер генә баш белән очасың?

— Кризис! Өч башны туендырып булмый!

• • •

— Хакимиятне сүккәнче — үзегез эшләп күрсәтсәгез әйбәтрәк түгелме?

— Яхшы, әйдәгез, шулай итәбез.

— Ә монысы инде хакимиятне бәреп төшерергә өндәү дип атала.

• • •

Рәсәй белән Украинаның футбол буенча Европа чемпионатында бертөсле "уңышка" ирешүләре, аларның чыннан да тугандаш халык икәнлеген исбатлады.

• • •

Казан мэриясе, борынгы кешеләрнең тукталып яшәгән урыннары хәзерге кебек түләүле булганлыгына басым ясыйлар.

• • •

Электрон сигаретлар тартуларын ташларга теләүчеләр өчен чыгарылган булса, электрон китаплар исә укуны ташлар өчен дияргә нигез бар.

• • •

Начальникка катгый шарт куйдым: хезмәт хакымны күтәрмәсә, мин эштән китәм. Тарткалаша торгач, уртак фикергә килдек: ул хезмәт хакымны арттырмый, мин эштән китмим.

• • •

Төрмәгә тикшерүчеләр килә. Берсе төрмә начальнигыннан сорый:

— Ни өчен сездә качулар күзәтелми?

— Һәр көнне иртән, тоткыннарга иректә бәя күтәрелү турында хәбәр биреп торам.

• • •

Начар кешеләр, яхшы кешеләрне саклагыз: исегездә тотыгыз — сез алар аркасында яшисез!



КАЧКАН ИНВЕСТИЦЯЛӘР

Эдуард Даутов атлы бер бәндә Татарстанда яшәүчеләрне баетырга булган. Үзен эшләре шәп баручы трейдер итеп күрсәтеп, ул төрле кешеләр белән гомуми суммасы 160 миллион сум тәшкил иткән контрактлар төзегән. Берникадәр вакыт дәвамында Даутов, клиентларны ялган отчётлар ярдәмендә алдап, аларны биржада үзенең табышлы эш итүенә ышандырган. “Алтын таулар” көткән беркатлы хыялыйлар арткан акчаларын кире таләп итә башлагач, “трейдер” инвестицияләр белән бергә табан ялтыраткан. Хәзер “биржа уенчысы”н суд эскәмиясе көтә.

ЮЛ РЕКОРДЫ

Чиләбе өлкәсендә яңа гына салынган юл гадәти булмаган рекорд куйган. 300 миллион сумга төшкән трасса... өч ай эчендә ишелеп төшкән. Төзелеш кагыйдәләренең бозылуын тапмаган өлкә юл-транспорт министрлыгы бу хәлгә... чишмәләр гаепле, дип аңлаткан. Инженер разведкасы мәгълүматларына караганда, җир астыннан су бәреп чыгып юлны “юып” төшергән. Төзелешнең подрядчигы – “Южуралавтобан“ акционерлык җәмгыятенең тарихы белән таныш кешеләр бу хәлнең фирманың гамьсезлеге нәтиҗәсе дип уйлыйлар. Моңа кадәр бу оешма асфальтны кар өстенә җәйгән өчен җаваплылыкка тартылган булган инде.


КАБЕР БӘЙГЕСЕ

Венгриядә кабер казу буенча тизлеккә ярышлар уздырылган. Бәйгедә икешәр казучы кергән 18 команда катнашкан. Дәрәҗәле жюри тизлекне генә түгел, кабер өстендәге таучыкның матурлыгын да бәяләгән. Венгрия каберчеләр ассоциациясе белдерүенчә, профессиянең дәрәҗәсен күтәреп, шулай итеп кабер казучылар сафларына күбрәк яшь, таза егетләрне тартмакчылар. Яшь кадрлардан башка бу тармакның үзенең дә исән калуы икеле.


Алексей МАМАЕВ



Виктор ФЁДОРОВ









Рәфкатъ РЫСАЕВ

АДӘМ-ҺАВА БАЛАСЫ БЕЗ

Нәсел тамырлары көчле,
Буыннан-буынга күчә.
Яхшысын да начарын да
Кеше һаман сөзми эчә.

Тарих шаһит: сусын кайтмый,
Илләр шашып сугышмаса.
Ир белән хатынның хәтта
Көе килми ызгышмаса.

Борынгыдан канга сеңгән
Безнең шулай буласыбыз.
Оҗмахта яши белмәгән
Адәм-һава баласы без.



ТИШЕК КОПЧӘК

Александр АЛЁШИН



УРЫН ЮГАЛТУ

Берзаман, эшкә килгәч, Бөгелмә шәһәр суды рәисе Наил Хәертдинов ышанмаслык хәлгә тап була. Аның «Стоянка запрещена» билгесе белән тамгаланган шәхси тукталу урынында чит машина килеп туктаган. Аның йөртүчесе Андрей Ермолаев аптырап калган судьяга үзенең 90 яшьлек әбисен – сугыш ветеранын төшерергә тукталганын аңлата – юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча аның моңа тулы хокукы бар. Тик бу кагыйдәләр шәһәрнең баш судьясы өчен язылмаган, күрәсең. Ачуы чыккан Хәертдинов үзенең йөртүчесенә «җир бит»нең автомобилен биккә куярга, һәм гаишниклар чакыртырга әмер бирә. Күз ачып йомганчы килеп җиткән инспекторлар судьяның кәефен кыручыга машинасын дөрес урынга куймаган өчен 500 сум штраф салалар. Беренче группа инвалидны төшергәндә берниндидә кагыйдә бозмавы беркемне дә борчымый.

Тик Ермолаев кимсетүне онытa торганнардан түгел: кеше хокукын яклаучы һәм инспекторлар өстеннән шикаять яза. Гаҗәп хәл: аны игътибарсыз калдырмыйлар. Татарстанның юл инспекциясе штрафны гамәлдән чыгара, суд бинасы янындагы законсыз куелган юл билгесен алырга карар кылына, ә «тырыш» гаишникларга карата тикшерү кузгатыла.

Татарстан судьяларының Квалификация комиссиясе дә үз тикшерүен уздыра. Ул, судья үзен болай тотарга тиеш булмаган, дигән нәтиҗәгә килә. Наил Хәертдиновка, үзе теләп, эштән китү турында гариза язарга туры килә.

Менә шулай урамдагы парковка урыны өчен көрәшеп, эш урыныннан коры кала.

Гомәр ДӘҮЛӘТШИН



Эрнест ДЫШАЕВ

ИХ, МАТУР БУЛАДЫР ЖӘЙЛӘРНЕҢ АЙЛАРЫ!

Василий АЛЕКСАНДРОВ



Игорь КИЙКО



ЖӘЙ – УЛ...

...җиңелчә киенеп, икенче җенестәге кешенең килеш-килбәтен бәяләп булганда.

...ябыгасы да булмаган чор.

...өске кием эчкесенә тартым булганда.

...исерек килеш урамда йоклап, үлмичә калганда.

...кичә иң башлары пешеп, ә бүген аяк өшегәндә.

...черки кунган сәбәп белән тиктомалдан кешегә сугып алганда.

Илдар НӘФИЕВ





Антон МАКУНИ

ЮЫНДЫРУДАН КИЛГӘН БӘХЕТ

Ишектә кыңгырау. Трынькин ишекне ачып җибәрә, анда ике сабый бала белән бер әби басып тора.

— Сезнең юыну бүлмәсе кайда? — ди кунак.

Трынькин, уйламый-нитми, бармагы белән сораган җирләренә күрсәтте. Бүлмәдә су агызган тавыш һәм шатлыклы балалар чыркылдавы ишетелде. Трынькин, аптырап, иң башларын гына җыерды.

Ярты сәгатьтән соң, юынып йөзләре алсуланган кунаклар чыкты да, Трынькинга рәхмәт әйтеп, китеп бардылар.

Ләкин ул аларның артларыннан ишекне бикләргә өлгермәде, яңадан кыңгырау шалтырады. Бусагада ике зур юл сандыгы күтәреп, бер ир кеше басып тора иде.

— Юыну бүлмәгез кайда? — дип сорады керүче. — Сулдамы? Уңдамы?

Күзе маңгаена менгән Трынькин бүлмәгә күрсәтте. Әлеге ир, сандыгындагы керләрне ваннага бушаттып, юарга кереште.

Эшен бетергәч, кунак фатирдан чыгып китте.

— Җитәр! — диде Трынькин, тегенең артыннан ишекне япкач. — Бүтән беркемне дә кертмим! Нинди хокуклары бар аларның сорамый-нитми монда үз эшләрен эшләп йөрергә?..

Шулчак тагын шалтырау. Ишек катында яше утызлар чамасындагы матур гына ханым басып тора...

— Гафу итегез, — дип башлады ул сүзен бераз оялыбрак. — Мин белдерү буенча...

— Нинди белдерү буенча? Мин белмим дә...

— Менә, — ханым аңа ак кәгазь тоттырды.

“Хөрмәтле гражданнар! — дип укый башлады Трынькин. — Сезнең районда кайнар су бирүне туктату сәбәпле, барлык юынырга һәм керләрегезне уарга теләүчеләр миңа килергә мөмкин. Түләүсез! Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында!” Ахырында Трынькинның адресы язып куелган.

Трынькин, кашларын җыерып, уйга калды. Аның белән кем шулай шаяртырга мөмкин?.. Шул вакыт ул күптән түгел эшендә булган бер хәлне исенә төшерде. Эштәгеләр, байтак районнарда кайнар су бирү бетәчәген белеп, ә Трынькин яшәгән йортта андый кыйтыклык булмаячагын ишетеп, сәер генә көлешкәннәр иде... Ну, кабахәтләр!..

— Мин, ахрысы, китәрмен инде, — дип, үзенең әле һаман көтеп торуын искә төшерде ханым.

— Юк, — диде Трынькин. — Сез ни... Үтегез, үт, юыну бүлмәсе — сулда, рәхим итегез...

Ханымның юынып чыгуын Трынькин чәчәк бәйләме белән көтеп алды...

— Гафу итегез, Сез миңа керү белән ошадыгыз, ә юынып чыкканнан соң — бигрәк тә. Сезне мөмкинме кафега яки театрга чакырырга? Ләкин кияүдә булмасагыз гына...

Ханым елмаеп:

— Мин кияүдә түгел... Сез дә миңа ошадыгыз... Мин сезнең белән рәхәтләнеп барам. Кафега булса да, театрга да... Тик менә...

— Нәрсәгә уңайсызланасыз?..

— Сездә юынырга минем олы апам гаиләсе белән килсә, мөмкинме? Аларның өендә су инде айдан артык юк. Сез каршы түгелме?

Трынькин шатлыгыннан башын селкеп куйды.

— Риза! Бик теләп риза!




Николай ВОРОНЦОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

КӨЛКЕ КАМЕРАСЫ





ТОКЫМЫ КОРГЫРЫ

Түбән Камадагы 4 нче номерлы төзәтү колониясендә ике ел буе тоткыннар өчен кафе эшләп килгән. Анда иректән мәхрүм ителгән бичаралар бай меню ашларын татып, күңелле итеп вакыт уздырганнар. Бушлай түгел, әлбәттә, ә башлыкның урынбасары Э. Абзаловның кесәсенә тамып барган өстәмә түләү өчен. Кафе эшләү дәверендә аның «хуҗасы» миллион сумнан артык акча үзләштергән. «Эшмәкәр»гә каршы җинаять эше кузгатылган.

• • •

Татарстанда ифрат сирәк очрый торган хәл булган. Ришвәтче профессор ике ел ярым срок алган. Аны имтиханын бирә алмаган студент «саткан». Яңадан бирү өчен фән әһеле 4,5 мең сум сораган. Имтиханга студент оперативниклар күзәтүе астында киткән. Соңыннан профессорның 23 студенттан шундый ысул белән имтихан «кабул итеп», кесәсенә 94 мең сум салганы ачыкланган.

• • •

Баш медицина-социаль экспертизасы бюросында эшләүче ике ханым эре мошенничествода тотылган. Алар инвалидлык белән «сәүдә иткәннәр»: кемгәдер группа алуда ярдәм итәргә алынганнар, кемгәдер вакыты чикләнмәгән инвалид статусы вәгъдә иткәннәр. Шәхси мәгълүматлар һәм диагнозлар белән танышып, ханымнар мәсьәләне алар катнашыннан башка чишәрдәй «клиент»лар сайларга тырышканнар. «Хезмәт күрсәткәннәре» өчен алар 80 нән 180 мең сумга кадәр сораганнар. Тик килешенүләр һәрвакыт үтәлмәү сәбәпле, 12 алданган кеше полициягә мөрәҗәгать иткән.

• • •

Алабугада ач караклар ресторанны басканнар. Бөтен кешенең күз алдында камыр ризыклары өелгән подносны эләктереп киткәннәр. Ләкин ерак китә алмаганнар – полицейский аларны тоткакарлаган. Әйтергә кирәк: шул арада караклар өч сумсаны ашап өлгергән.

Виктор ФЁДОРОВ

Алексей МАМАЕВ





МАҖАРАЛЫ СӘЯХӘТ











Киләчәгеңне әйтеп бирәм!













Александр АЛЁШИН

ЯЛГЫШКАНЛЫККА РӘХМӘТ БЕЛДЕРҮ

Үзенең гомере буе корреспондент булып эшләү дәверендә, Марсель Зарипов өчен иң катлаулы һәм мәшәкатьле нәрсә — исем-фамилияләрне бутамау, фактларны дөрес тасвирлау саналган. Кызганычка каршы, гәҗит материалларында, хәтта кечкенә мәкаләләрдә дә бу ялгышлыкларның әле берсе, әле икенчесе чыккалап куя. Шуңа күрә мондый чатаклыклар кемнәрнеңдер ачуын чыгарган очракта, давыл куптарып, гәҗиткә язмасыннар өчен, җайлап-майлап гафу үтенә белү дә кирәккәли. Әлбәттә, югары профессиональлекне саклаган хәлдә.

Телефоннан аңлашу, гадәттә, менә мондый формада бара:

— Гафу итегез, сез корреспондентмы?

— Әйе. Тыңлыйбыз.

— Беләсезме, сез бүгенге мәкаләдә инициалларны бутагансыз...

— Ә-ә... Шулаймыни?.. Фамилия — дөресме соң?

— Анысы — дөрес.

— Аллага шөкер икән.

— Аңламыйм, ни өчен Аллага шөкер?

— Әгәр дә фамилиясе дә дөрес булмаса, эшләр катлаулыракка китәр иде. Шулай бит?

— Әлбәттә... Дөрес әйтәсез... Бу турыда без ныгытып уйламаганбыз. Рәхмәт!

Кайчагында ялгышлык инициалларда гына түгел фамилиядә дә киткәли. Ул вакытта Зарипов фактларның дөресме-түгелме икәнлеген төпченгән булып кылана.

— Төгәл, — диләр шалтыратучылар. — Бер генә өтеренә дә һәм санына да бәйләнерлек түгел.

— Менә шуңа шатланыгыз. Язу-сызу эше бик катлаулы нәрсә, монда фактларны да бутарга мөмкиннәр. Ул чагында сез үзегезне бөтенләй таный алмас идегез. Әйеме?

ИСЕМЕ БЕЛӘН ФАМИЛИЯСЕН БУТАГАН

Марсель Зарипов “Чаян” журналына кызык һәм гыйбрәтле мәкаләләрен китергән. Ул вакытта җаваплы сәркатип булып Камил Кәримов эшли. Марсель сорый моннан:


— Әйт әле, син кем — Камил Кәримовмы, әллә Кәрим Камиловмы?

— Әй, Марсель абый, Марсель абый, син хәтереңне төпсез иләктән иләп киләгәнсең, кешеләрнең исемен фамилиясе белән бутыйсың!


— Менә минем кебек тере классик булгач, син нишләрсең икән, үзеңнең әтиеңнең исемен дә онытырсың әле.

Язманы Алмаз ХӘМЗИН әзерләде.

Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 9, 1972



– Мәктәпне бомбага тотуыгыз дөресме?
– Әйе, мәктәпкә үпкәләрем бихисап!




Валентин КОСМЫЛИН, «Чаян» № 16, 1978



Леонид НАСЫЙРОВ, «Чаян» № 14, 1977

– Ә аңа менә эшсезлек янамый!

Суфия НАСЫЙРОВА, «Чаян» № 16, 1976



– Нәрсәгә кабаланалар инде, кышка кадәр ерак бит әле!

УКУЧЫ ШИГЫРЬ ҖИБӘРДЕ

Манара каргышы

Бу хәл булды күптәннән бик матур язгы айда,
Мотак ягы — өч мәчетле зур авыл Төгәлбайда.
Апрель ахры: куләгәдә, һәм текә ярларда
Кызу кояшта ятадыр эремәгән карлар да.
Бик озак карап тордык фаҗигасен авылның,
Биек урыннарыннан Кәримә әби тавының.
Аякларда чабата, гәләфи ыштаннары,
Мәчет янына җыелган комсомол куштаннары.
Мәчет башына менде җырлый-җырлый өчесе,
Актык минутын яшәде манараның кечесе.
Мотыйгулла бау очын астагыларга ташлый,
Ә икесе пила белән манара кисә башлый.
Пила елый, ыңгыраша, утмидер тешләре,
Манара имән булганга, барып чыкмый эшләре.
Персидәтел акырадыр: "Әй син, малай, чап!" — дип, —
Балта белән манараның сыртына бир давай!" — дип.
Балта имән кимерә, йомычкалар ялтырый,
Безнең мескен манарабыз, ыңгыраша, калтырый.
Өстән берсе шатлыгыннан пиласын ташлады,
Һәм манара елый-елый авып төшә башлады.
Авыл халкы тынып калды, ни эшләргә белми,
Күңелләре сизгән кебек, бер этләре дә өрми.
Чулак Кыям карап торган лапасы башыннан,
Ә кич белән колак каккан персидәтел ашыннан.
Крестком абый хатыны: "Хәзер анда барам, — ди. —
Менә шушы кисәү белән мин башларын ярам", — ди.
Манара кисүчеләр сугышта ятып калды.
Мотыйгулла әле исән, хәтта орден да алды.
Мәчет зур хәзер монда, мактыйлар кибетләрен,
Арзанга алып була, ди, симез дуңгыз итләрен.
Һәр йортка газ керткәннәр, әйбәт кенә юллары,
Инде дуңгыз симертәләр кайберсенең уллары.
Кайберәүләр җирәнә икән дуңгыз ашыннан,
Холодец әйбәт була, ди, чучкаларның башыннан.
Яшьләре бик тырыша, ләкин һич чыкмый җае —
Авылда пока бер генә яңа татарның бае.
Кайсысында машина бар, трактор яки аты,
Бик күп йортта кайнап тора самогон аппараты.

Сөләйман ШАКИРОВ,
хезмәт ветераны, 80 яшь.

“Чаян” күнекмәсе

ЙӨЗ УТЫЗ АЛТЫНЧЫ ТУР



Хәзерге вакытта ике мәзәкнең берсе шул хокук саклаучылар турында инде. Менә бу “күнекмә”дә күрсәтелгән бирем дә уачкка бензин өстәргә тиеш дигән идек, шулай булып чыкты. Башкача мөмкин түгел, карагыз әле бу “капкорсакларга” — бер аяклы җинаятьче дә качып котыла бит болардан.

“Күренеп тора — яхшы кешеләр, — дип язган “Чаян”дагы һәр биремгә җавап җибәреп торучы С. Гомозов, Түбән Новгород якларында яшәп, безне һәрдаим укучыбыз. Дөрес әйткән, чөнки яхшы кешедә барысы да күп булырга тиеш. Шул ук авторыбыз өстәп шигырь дә сырлап куйган: **“Безнең барысы да шундый — ЮХИДИда, нечкәләр юк ни фига да!” “Өчесе дә таза — афәрин, уртадагысы шуның татарин!”** — дигән Арча якларыннан килгән җавап. Тик менә исемен генә атамаган.


Арткы планда шәрә сурәт,
Нишләргә белми нәрәт.
Ертырга кирәк плакатны —
Ә “шәрәләр” — атаклы:
Кызы — генералныкы — артист
һәм шеф малае — Данис!
Ала алмый шуны “өч бугай”,
Инде бер ел йөриләр бугай.

Бу шигырьне Казан кешесе Рамил язган. Шәһәрдән шагыйрьләр чыкмый, диләр. Бар икән бит алар. Әле ниндиләре?.. Рамил кебекләр булганда татар юмор һәм сатирага саекмас! **“Өч баһадир — уртадагысы Бари — командир”,** — дип, үзләренең Баулыдагы дустын танып язган шул якларда яшәүче Р. Сибгатуллин. **“Алло! Тоткарларга барырга? Хәзер, ләкин без машинага сыя алмыйбыз — кечкенә ул безгә”,** — дигән сүзләр әйтә сыман сул яктагысы — телефонлы юанрагы. Әлеге сөйләшүгә җавап әйткәндәй: **“Бу машина түгел — мусоровоз”,** — ди Чаллыдан И. Гарипов. **“Буйлары белән иңнәре — бер чама”,** — дигән Тольяттидан Е. Буйко. **“Безнең хезмәт авыр һәм куркыныч. “Макдоналдс” саклау безнең төп бурыч”,** — җырдагыча шигъри һәм көйле килеп чыккан Кама Тамагында яшәүче Л. Госманованың фразасы. **“Получка биргәннәр — юлга чыккан бирәннәр!”** — монысы Яңа Чабаксар шәһәреннән Л. Куманов тәрткесе. **“Корсакларын кызганмый хезмәт итәләр!”** — дигән Алабугадан Е. Дунаев. **“Аларның күлмәк астында биш кат бронежилет!”** — дип, алар яклы булып кылана Сарманнан Т. Заһидуллин. **“Алар бу хезмәткә 100 килограмм элек килгәннәр иде”,** — менә монысы искиткеч төгәл һәм кызык шаярту. Яшел Үзәндә “Чаян”ны укып яшәп ятучы Н. Киреевның кулын кысабыз.

Инде яңа тур тәкъдим итәбез. Бу юлы бик “тешләш” җаваплар килде, рәхмәт. Бердәм дәүләт имтиханнары — БДИ тапшырасы түгел, курыкмыйча җавап бирегез!



КОРОЛЬЛӘР БУЛДЫРА!



Валентин ДУБИНИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



Илдус АЗИМОВ



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Порошенко Румыниягә рәсми визит ясаган. Ул, чегәннәрдән акча сораучы, дөньяда беренче кеше булып чыккан.

• • •

Ике эшмәкәр очраша:

— Син салым түләдеңме?

— Әйе.

— Йоклыйсыңмы?

— Юк.

— Нигә?

— Салым салучыларга, салымны түләр өчен кайдан акча тапканымны аңлатам...

• • •

Ике дус кыз эч серләре белән бүлешә:

— Ул синең белән инде ай буе очрашамы? Әйт әле, ул синең кулыңны сорадымы?

Сердәше башын аска иеп:

— Кулларымны... юк әле...

• • •

Тарих укытучысы:

— Рәсәйдә гомер бакый өч сорау булды: беренчесе — “Кем гаепле?”; икенчесе — “Нәрсә эшләргә?”. Өченчесен кем белә?

Соңгы парта артында утыручы укучы:

— Син мине хөрмәт итәсеңме?

• • •

Чыгарылыш класс укучысы:

— Минем әле хәтеремдә әнинең мине беренче сыйныфка алып килүе. Һәм чыгарылыш кичәсеннән соң, әтинең мине өйгә ничек алып кайтып китүе.

• • •

Керү имтиханында абитуриенттан сорыйлар:

— Сез Пушкин белән танышмы?

— Юк.

— Некрасов, Гоголь, Чехов, Толстой белән?

— Алар белән дә таныш түгел.

— Сез ирекле!

— Ә сездә шулай танышлык белән генә алалармыни?



Илдар НӘФИЕВ

Марат КАСЫЙМОВ

Кем гаепле?

Алтынов, маңгаендагы салкын тирен сөртеп, телевизордан күзен алды. Әле генә криминал хроникада тирә-юнь мохитендәге тышкы форманың эчке бизәлеше департаменты җитәкчесе Башляев турында сюжет булып алды. Аның белән Алтынов берничә мәртәбә "үзенә алып калу" вариантлары үткәргән иде.

Алтынов күз алдына әле һаман оператив рәвештә төшерелгән кадрлар килеп баса: Башляевның шәһәр читендәге йортында тентү үткәрәләр, өстәлдә бәйләм-бәйләм долларлар, ә бөтенләй җебеп төшкән түрәнең ап-ак кулларына ялтырап торган богау кигезеп, өеннән алып чыгалар.

"Безгә тотынганнар! — диде Алтынов. — Башляев беренче сорау алган вакытта ук сыгылып төшәчәк һәм барыбызны да сатачак, һичшиксез! Үзеңнән гаепне читләтү зарур..."

Аның каршына "нәрсә эшләргә?" дигән сорау килеп басты. Бераз уйланып торганнан соң, күңеленә бер фикер килеп, компьютер каршына утырды. Ул электрон элемтә аша кая кирәк шунда имзасыз хат юлларга булды.

"Бүтән департаментларда нәрсә кыланалар, барысын да әйтеп язам. Исемнәрен атыйм... Кемнең кем икәнлеген белсеннәр. Хөкем эшләре башланганчы вакыт үтә торыр. Ә мин, тыныч кына, балык кебек суга чумам. Койрыгымнан да тота алмаячаклар. Ходай Тәгаләгә калса — аның белән үзем килешермен..."

– Абруйлы органнарның исәпкә алуларын үтенеп, — дип тыкылдата башлады ул клавиатура төймәләрен. – Туктале, туктале, — диде Алтынов, үз-үзенә шикләнеп. — Алар бит бу хәбәрнең каян килгәнен шул моментта ук расшифрлуют...

Элекке җай белән эш итәргә кирәк! Алтынов күн перчаткаларын киде, алдына ак кәгазь куйды, ручкасын сул кулына алып кыек-мыек язарга тотынды: "Абруйлы органнарның исәпкә алуларын үтенеп..."

Алтынов хатында энәсеннән-җебенә хәтле үзе белән уңышлы эшләр башкарган начальникларның нинди осталыкта кыңгыр гамәлләр кылганнарын яза башлады: Кадиловның ялган тендерларын; Әхмәтовның вак эшмәкәрләрне төрле ясаклар белән тинтерәткәнен; Мәмушевның оста алдап төзелгән сметаларын; үзенә алып калу буенча тиңнәре булмаган Фатиховны һәм хәтта Вәли Вәлиевичның үзен, чөнки бюджет акчаларын Алтынов ярдәме белән җайлы гына үзенең хатынының фирма счетына күчерә торган иде.

– Алар барысы да минем каршыда җавап бирәчәкләр! — дип кызып китте Алтынов. — Ришвәтчеләр! Халык акчасы хисабына яшәүчеләр! Кабахәтләр!"

Иртән ул бу мөрәҗәгатьне тиешле җиргә җибәрде. Ә инде төштән соң аның бакчасындагы кабинетта тентү бара иде. Төргәк-төргәк долларлар, оператив төшерүләр, кул богаулары... Тегеләрнеке төсле.

Кич белән КПЗда Алтынов чүт еламый гына башындагы чәчен йолкый иде.

— Җүләрнең җүләре мин, ахмак! — дип шыңшый иде ул. — Күпме яшәп, күпне күреп акыл кермәгән нәрсә. Мин генә түгел бит Башляевны телевизордан карап утырган, шуны аңламаганмын. Миннән алда күреп, кем өлгергән хәбәр бирергә? Минем монда эләгүемә кем гаепле? Кадилов, Әхмәтов, Мәмушев? Ә бәлки Вәли Вәлиевичтер?..



Василий АЛЕКСАНДРОВ





ЗАМАНА ФИКЕРЛӘРЕ

Хатын-кыз модасының иң гаҗәеп ягы – киемгә тукыма никадәр кимрәк китсә, ул шулкадәр кыйммәтрәк бәяләнә.

Киенәсең икән – иске фоторәсемнәрдә җүләр булып күренмәслек итеп киенергә кирәк.

Яңгыравыклы мода – ул кием кибетендә бәя күргән ирнең авазы.


Хатын-кыз сумкасында иң мөһим нәрсә – анда аш салынган банканың сыюы.

Хатын-кыз башкалар кебек киенергә тели, ләкин башкалар кебек киенгәч, аларның да үзе кебек киенгәнен күреп җәфалана.

Иң аз чыгымнар белән иң күп мәгълүматны мини-юбка гына бирә ала.

Кием барлыкка килү белән тыйнаклык юкка чыкты.

Валентин ДУБИНИН



Сергей ЕРМИЛОВ



Заһир ХӘКИМОВ



– Акылына килә башлады бугай – төбенә кадәр төшми!

Александр КОСМЫЛИН





МАТАШТЫРАЛАР...

Кадерле Чаян! Күптән түгел генә “Билайн” сервисына тоташтырылган телефон исәбеннән 62 сум акчамны алдылар. Килгән смс-хәбәр мине бөтенләй аптыраштa калдырды: “RURU” түләү сервисы бурычның тулаем түләнгәне өчен рәхмәт белдерә”. Нинди бурыч? Кайдан һәм нәрсә өчен?

Оператор белән озаклап әңгәмә коргач, бераз төшенә башладым. “Билайн” хезмәте үзенең клиентлары өчен бик борчыла булып чыкты. Ниндидер түләү үткәрәсе булса, “Билайн” партнеры “RURU” ярдәмгә киләчәк. Кирәкме-юкмы, сорап тормый гына калган бурычны телефон исәбеннән салдыра да куя. “Билайн”ның һәр клиенты өчен махсус аванс счеты да каралган икән.

Исемлектә коммуналь түләүдән алып парковка өчен түләүгә кадәр бар. Күрсәтелгән махсус хәрефләр җыеп кына бөтен шартларны автоматик рәвештә кабул итәсең.

Күрәсең, кесәмдә яткан телефон үзе җыйган әлеге махсус символларны. Тик мин нәрсә өчен түләгәнемне никадәр тырышсам да, белә алмадым, кинога билет алганмын яисә газга түләгәнмендер... Телефон архивында да бернинди мәгълүмат сакланмаган. Бурычны түләргә кирәк дип кисәткән смс-хәбәрләр дә булмады. Сорау артыннан сорау туа...

“Билайн” сервисында еш кабатлана торган шундый девиз бар: “Телефоннан акча алу җиңел!” Ә мин нәрсә өчен алынганын ачыклау бер дә ансат түгел.

Л. НИКОЛАЕВА

КАЗАН

ЯРЫМ-ЙОРТЫ ЮЛЫ

Кадерле редакция! Безнең бистәдә “ирекле” мәҗбүри итеп җыелган салым исәбенә барлык юлларны да төзекләндерергә сүз биргән иделәр. Сагаюлы карашларга карамастан, эш башланып китте. Дөрес, үзенчәлекле алым белән...

Әйтик, Стекольная урамы үтеп кермәслек пычраклылыгы белән дан алган урам. Хәтта, шунда яшәүче халыкка тирес алып килгән КамАЗ машиналары да үтеп керергә батырчылык итмәде. Узган ел юлның яртысына вак таш җәйделәр дә, шуның белән акча тәмам, дип, китеп бардылар. Хәзер исә безнең урам бистәнең гаҗәп бер урамына әйләнде дә куйды. Юлның ике башы керә алмаслык пычрак, ә уртада — сибелгән вак таш! Тик шунысы аяныч: салым түләгәндә ярты сумманы гына түләп булмый бит, штраф чәпиләр. Юл төзүчеләргә дә яртысын гына эшләгәннәре өчен штраф чәпәсәләр иде икән.

В. СӘГЪДИЕВ

ВАСИЛЬЕВО

БАТАБЫЗ!

Чаян дус! Гадәттә, шәһәр халкы, ләззәтләнеп, табигать кочагында соклана алмавына зарлана. Ә менә безгә, балалар иҗат йортыннан ерак та түгел яшәүчеләргә, табигый матурлыкка соклану өчен ерак барасы түгел. Тәрәзә каршында ук зур сазлык хасил булды. Янына килерлек түгел: черки болыты, бака туе, сасысы...

Кайчандыр биредә бер дә кипми торган күлдәвек кенә иде. Хәзер исә, безнең шикаятьләргә битараф коммуналь хезмәткәрләре аркасында, янына килмәслек сазлык. Әлбәттә, бюрократ селкетүләренә ерак әле, ләкин, баткаклыкка чуму ихтималы бик якын...

Ю. ХӘМИДУЛЛИН

ЧАЛЛЫ

ФИНАНСЛАР БАЛАНС ҖЫРЛЫЙ, ҺОП–ПА!


Хөрмәтле редакция! Урамның караңгы чатын айфон белән яктыртуның начар билге икәнен беләбез. Тик шулай да башка чарабыз юк. Узган ел “Соловьиная роща” комплексына күчкәннән бирле яктырткычларның әсәрен дә күргәнебез юк. Подъездларны караңгыда капшап табарга мәҗбүрбез. Шунысы гаҗәп: бөтен яктырткыч системасы да төзелгән һәм әзер, тик эшләми генә. Әйтүләренә караганда, ООО “Грань” төзү идарәсе әле дә булса бу системаны шәһәр балансына күчерә алмый, сәбәбе — шәһәрнең акчасы юк. Ел ярым әзер документлар пакеты ике арада йөри. Әлегә, финанслар ”баланс җырлаганда”, начар билгеләргә буйсынмый яши бирәбез.

М. МОТЫЙГУЛЛИН

КАЗАН



Александр БУЛАТОВ



Владимир ИЖБОЛДИН



Рушания ГЫЙЛАҖЕВА


Лифтлы бәхет

Кинәт лифтларга түләүне
Үзгәрттеләр бер җайга:
Инде аның мәйданыннан
Хак сорыйлар бу айда.


Лифтта мәйдан йөриме?
Әллә кешеме йөри?
Түлик элеккечә дисәк,
Бәяне ЖЭКлар көйли.

Инде аста яшәүчедән
Акча алу башланды.
Югыйсә лифтка керәп ул
Бер дә аяк басмады.

Мондый хәлдән туйган халык —
Сүгенәләр — кругом мат!
Әйтерсең, кеше түгел без —
Хәерхаклы банкомат...



Михаил ЛАРИЧЕВ



Вячеславс ШИЛОВ


Ышанам!

Кадерлем, син нишләп шундый көчсез һәм йомшак соң? Башкаларның да төрле чагы була, алар тора бит. Ә сиңа тәрәзәдән җил иссә дә давыл. Инде әни дә кабатлый-кабатлый арып бетте: «Безнең язмышны кабатлама. Башканы тап үзеңә. Кемгә кирәк синең тугрылыгың?» Ә мин кабатлыйм, кабатлыйм шул аларның язмышын. Мин малның кадерен беләм, кирәк булса тегә дә, бәйли дә алам, балта түтәсеннән аш пешерәм. Ә син менә кайчан нык, ышанычлы булырсың икән? Башкаларга буйсынып, читләр турында кайгыртырга җитәр инде. Үз-үзеңне ихтирам итә башларга вакыт. Әллә син агачтанмы, берни дә тоймыйсыңмы? Тик мин, кадерлем, болай берөзлексез борчылып, билгесезлектә яшәүдән туйдым инде! Сиңа таянып ышаныч белән яшисем килә!

Тик шулай да мин өметләнәм, мин ышанам, мин беләм – кайчан да булса син күтәрелерсең, кадерлем минем РУБЛЬ!

Нажия БӘХТИЕВА







• • •

Бәләкәй генә малай әтисенең түшәм буяганын карап утыра. Әнисе моңа әйтә:

– Улым, карап утыр, өйрән, үскәч әниеңә булышырсың.

– Ә нигә, ул вакытка кадәр түшәмне үзе буяп бетерә алмыймыни?

• • •

Пушкин һәйкәле янынннан узып баручы экскурсоводтан сорый:

– Әйтегез әле, кемгә куелган һәйкәл бу?

– Пушкинга.

– Теге "Муму"ны язган кешеме?

– Юк. "Муму"ны Тургенев язган.

– Аптыраш. "Муму"ны Тургенев язган, ә һәйкәлне Пушкинга куйганнар?

• • •

Өч кыз: оптимист, пессимист һәм реалист шопингка киткәннәр. Оптимисты кирәгеннән озынрак джинсы сатып алган. Пессимисты – киңрәкне. Ә реалисты – будыргычлы юбка.

• • •

Һәр ир кешенең тимер баганасы бар һәм аны бернинди дә хатын-кыз бөгә алмый. Бер генә юл кала — кисү.

• • •

Кибет. Касса.

Сатучы сорый:

– Сезгә тоткалы пакетмы?

– Юк! Аяклыны бирегез, кырыемда йөгереп барсын!

• • •

Түләү квитанцияләренә караганда, зиннәтлелек өчен салымны барыбер керткәннәр икән.

• • •

Кызык! Кем белән хыянәт итә икән "барлык" ирләр? Безнең "барлык" хатыннар тугрылыклы бит чүтеки?!

• • •

БДИнең (ЕГЭ) сере ачылган! Аны, кроссвордлар чишәргә, офис белгечләре әзерләү өчен керткәннәр икән!



Куптән түгел үзем өчен бер күңелсез нәтиҗә ясадым. Нишләптер мин яраткан бөтен нәрсә йә законсыз булып чыга, йә көтмәгәндә минем һәм тирә-юньдәгеләрнең сәламәтлегенә зыян китерә, йә җәмгыять кануннарына каршы килә башлый.

Тамбурда тәмәке тарту гадәте поездның пассажирларын һәм проводник-машинистларын турыдан-туры гүргә кертә. Мәктәптән илле метрдан якынрак урында сыра эчү укучыларны сыйныфлары белән эчкечелеккә китерә. Бернинди "Дом-2" һәм югары әхлак белән сугарылган сериаллар, бернинди Интернет баланың күңеленә кулымдагы сыра шешәсен күрү тирән җәрәхәт ясамый. Ә менә сыра пластик пакет эченә яшерелгән булса, балалар көтүләре белән китапханәгә – Габделҗаббар Кандалый шигырьләрен укырга йөгерәчәк. Хәзер бит элеккеге кебек балаңа тиешле җәза бирергә дә ярамый. Әгәр малаеңның кесәсендә сигарет тапсаң, сугенеп, аны җиңелчә чәпәләп аласың икән, иртәгә үк өеңдә "омбудсман" дигән серле абзыйның пәйда булуын көт. Күршеләр дә бик уяу, малаең үзе дә төшеп калганнардан түгел. Шуңа күрә баланы тәрбияләү бүгенге көндә бик кыйммәткә төшә. Мин үзем, мәсәлән, бу эштән күптән баш тарттым. Әнә, "Камеди клаб"лар, "Универ"лар тәрбияләсен.

Их, бар иде заманнар! Сөйгән кызың белән төнге Казансу дамбасы янында шампанский ачып җибәрәсең. Җылы төн, стаканда күктәге йолдызлар кебек күбек җемелди; шәрабтанмы, битне кытыклаган чәчтәнме башлар әйләнә... Юк шул инде, бу сихри эчемлек тә тыелган. Беренчедән, бу җәмәгать урыннарында спиртлы эчемлекләр эчү дип санала. Әгәр дә төнге икедә ресторан буфетында бер шешә шампанский алгансың икән, монысы инде эчкечелектән кырылуга тиң бер авыл. Ләкин авыл башка нәрсәдән кырыла: анда, хан заманындагы кебек, мичкә һаман утын ягалар. Югыйсә янда гына газ чыганагы. Газ үткәрергә торбалар юк, чөнки кыйммәт. Франциягә сузар өчен бар, ә өч чакрымдагы авылга кадәр юк. Эчкечелектән түгел, гарьлектән үлә халык, хөрмәтле хөкүмәт...

Кызым белән совет мультиклары карарга яратам мин үзем. Аны сы да ярамый — алар әхлак кануннарына туры килми һәм баланың психик сәламәтлегенә зыянлы икән бит. "Ну погоди!" — сукбайлыкны пропагандалау, законсыз гамәлләрне аклау. "Простоквашино" да — шул ук нәрсә. "Винни-Пух", "Леопольд", "Чебурашка" — монда да ниндидер вак мөртәтләр тәртип бозып йөри. Ә менә Дисней мультфильмнарын бернинди "16+" һәм "12+"ләрдән башка рәхим итеп карасагыз була. Анда беркем дә тәмәке тартмый, беркем дә югалмый. Ә ниндидер этнең башын ярганнар, койрыгын өзгәннәр йә тәпиен пешергәннәр икән — андый вактөяккә игътибар итмәскә дә була...

Һәм мин монда, тагын бер нәтиҗә ясадым. Әгәр халык, башын кашып, нәрсәдер төшенә башлый икән, аңа "яңа закон проекты" дип аталган сөяк ыргыталар. Сез чиновникларыбызның миллионлаган ришвәтләре белән илгә күпмегә төшүләре турында уйлана башладыгызмы? Мәгез сезгә "тәмәке тартуга каршы закон", фикер алышыгыз, шаулашып алыгыз. Лондондагы затлы сарайлар хуҗасының егерме квадратлы фатирлардан көлүе ошамадымы? Менә сезгә "сыра сатуны тыю турындагы закон" — бу сезнең өчен якынрак та, мөһимрәк тә. "Ну, погоди!"дагы тәмәке тартучы бүрене тыю тартмый торган карак министрны утыртуга караганда, җиңелрәк бит. Чөнки министрның хәтере калып, артыгын сөйләп ташлавы бар, ә рәсемдәге бүре ифрат та аз сүзле.

Инде соңгы нәтиҗә ясарга батырчылык итәр идем. Нәтиҗәләр ясау — ул җәмгыятьнең нигезен какшату, үз сәламәтлегеңә зыян китерү, хәрәкәт итү мөмкинлегеңне чикләү.

Шуңа күрә мин тагын телевизор ялгап куям, анда яраткан "Пусть говорят!" тапшыруын табам, аның шашынган кунаклары һәм кыланчык алып баручысына текәләм. Бу тапшыруны карап, тагын бер нәтиҗә ясап булыр иде, тик аны әйбәт сүзләр белән генә аңлатып булмаганга күрә, ул "Яла ягу турында"гы законга эләгә... Шуңа күрә бу юлы тыелып калыйк.

Илшат КӘБИРОВ



ЧАЯН шифаханәсе



Вячеслав БИБИШЕВ



Михаил ЛАРИЧЕВ

ҖАВАПСЫЗ СОРАУЛАР

Йөрәксез кешеләргә инфаркт яныймы?


Аек тормыш – алкоголизмның беренче стадиясе түгелме?

Диагнозлар туры килмәгәндә бергә яшәп буламы?


Әгәр дә пациент бернәрсә белән дә авыртмый икән, табибка диагноз кую авырмы?

Шәхес икегә бүленгәндә ялгыз булып буламы?

Хатын-кыз тәҗрибәле гинекологны берәр нәрсә белән гаҗәпләндерә аламы?




Вячеслав ШИЛОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Виктор ФЁДОРОВ



Игорь КИЙКО



Алмаз ХӘМЗИН

ХӘНӘФИ БӘДИГЫЙ КИЧӘСЕНДӘ ТУГАН ХИСЛӘР

Зур зал тулы халык –
Шыгрым, шыгрым.
Ялкынланып укый
Бәдигый шигырен.

Тыңлыйлар тын булып,
Таң калып, шаккатып.
Шигъренең куәтен
Юк-бар сүз белән
Булмыйдыр аңлатып:

Мәгънәсе еракка
Китә дә иртеп,
Боргычлап җаныңны
Кайтара тинтрәтеп!

Син шагыйрь, педагог
Һәм доктор да наук!
Көйләр дә язасың –
Мактанма алай ук!

Безгә дә калдыр эш,
Без ялкау түгел ич.
Җәлилне күтәрдең,
Безне дә күтәреш!

Кичәңдә кемнәр юк?..
Җамалчы икәнсең...
Шәп, малай, шигыре –
Мал духтыры, димәссең...


К. Кәрим килмәгән,
Исән бит, үлмәгән.
Әллә соң банкетың
Буласын белмәгән?..


Бәдигый, Бәдигый –
Син шундый – табигый!
75 тутырдың,
100 гә күп калмаган,
Иҗат ит арымый!

Алкышлар, алкышлар... –
Бәдигый кичәсе!
Булды бар нәрсә:
Тәм-томы, шәрабы.
Тик килми "эчәсе"!
Шигыреннән исердек!

Мин – эт, Син – мәче


Питерда яшәүче карикатурачы Виктор БОГОРАД белән Вячеслав ШИЛОВ этләр һәм мәчеләр турында китап чыгарырга уйлаганнар. Ул сүзсез рәсемнәрдән торачак, урыны белән күңелле, урыны белән ямансу, ә тулаем алганда – игелекле булачак. «Без альбом чыгарырга гына теләмибез, ә иясез, авыру йә усаллыктан зыян күргән, рәнҗетелгәннәргә ярдәм итәргә телибез», – дип яза безгә авторлар. Һәм бу кешелекле башлангыч турында мәгълүматны социаль челтәрләрдә таратуыбызны үтенәләр. Ә нишләп челтәрләрдә генә? Безнең укучылар да авторларыбызның яхшы ниятләре турында белсен әле!


Виктор БОГОРАД




Вячеславс ШИЛОВ

Вячеславс ШИЛОВ



Виктор БОГОРАД



Йолдыз ШӘРАПОВА

ХАЛЫК ӘЙТСӘ, ХАК ӘЙТӘ

"Без өйләнгәч, төн кыскарды", – дия иде әтисе, эше барып чыкмаса. Быел Габдулла Тукай исемендәге премиянең мактаулы исемен генә бирәчәкләр икән, акчасын бирмәячәкләр, ди. Шагыйрьнең 130 еллык юбилее уңаеннан һәм илдәге кризисны сәбәп итеп, лауреатларның һәрберсенә тиешле ярты миллионышар сумны элек Тукай исемен йөрткән колхозларга өләшеп, аларны торгызачаклар, аның исемендәге урамнарны төзекләндерүгә тотачаклар икән. Аннары Тукайның һәйкәлен дә яңа урынга – Печән базары тирәсенәрәк күчереп салачаклар, ди. Аның каравы, быелгы кандидатларның һәммәсе дә премия лауреатлары булачак, берсе дә төшеп калмаячак, ди. Ә бит аларның саны елдан-ел арта бара, быелгыларын санарга кулдагы бармаклар да җитми. Дөнья бетә, соңгы тапкыр бирәләр, диярсең... Бу хакта ишеткәч, премиягә кандидатлар исемлегендә беренчеләрдән булып торучы Фәнил Фаязның баш миеннән яшен тизлеге белән әтисенең шушы сүзләре йөгереп узды.

Танылган прозаик һәм шагыйрь Фәнил Фаязның бу исемлеккә бик керәсе дә килмәгән иде анысы, шактый зур түрә булган баҗае ай-ваена карамый, әйдәкләде: "Мин барында алып кал, аннары гел үзгәреп торган дөнья хәлен белеп булмый!" – диде. Баҗаен тыңлау файдалы икәнен яхшы белә, бу юлы да теләп ризалашты. Кандидатлар исемлегенә эләгү кыен булмады Фәнил Фаязга. Китаплары басылып, таралып китә. Кем әйтмешли, үз укучысын тапкан бәхетле әдипләрнең берсе. Классик ук булмаса да, арттагылар рәтендә дә сөйрәлми.

"Бәхетеңне керпе чакмасын, улым!" – дия иде әнисе, балачакта башыннан сыйпап. Бигрәк гаделсез инде бу дөнья: узган ел мактаулы исемен дә, уч тутырып акчасын да бирделәр ич әнә. Аңа җиткәч кенә нишләп үзгәрергә тиеш әле ул премия бирү тәртибе?! Әгәр үзенә Тукай премиясе тәтесә, олы улына яңа машина алам дип, вәгъдә итеп тә өлгергән иде шул, гөнаһ шомлыгы. Аннары хатыны да: "Әнә кешеләр диңгезгә бара, без өй тавыгына әйләндек инде..." – дип кыш буе колак итен ашады. Ул диңгездә ние калгандыр, атасы-бабасы барганмы? Ә Фәнил Фаяз: "Үз ягымда ямьле миңа бәрәңге бакчасы да..." дип җырлаучылар рәтендә. Аннары әни карчыкның өе дә бик искерде. Тукай премиясенә лаек язучы үстергән ана андый йортта торырга тиеш түгел, акчасы кулыма керсә, туган нигезне дә сипләргә исәп. Менә никадәр хыял берьюлы челпәрәмә килә түгелме соң? Үзеңнән башка кемне гаеплисең?!. Узган ел ук, иртәрәк аяк киенергә кирәк булган да бит... Үкенүдән ни файда, терсәк якын булса да, берәүнең дә тешләгәне юк әле. Дөрес, аның исеме дә зур, бик дәрәҗәле инде. Әнә ничек яңгырый: Габдулла Тукай премиясе лауреаты Фәнил Фаяз! Ләкин исеме янына җисеме дә булса...

– Тукта! Баҗаема шалтыратып карыйм әле. Ул бу яңалыкны белми калмагандыр. Чү, ул үзе шалтырата түгелме соң?!

– Алло! Алло! Баҗай!

Фәнил Фаяз күзләрен ачса, янында борчылган кыяфәттә хатыны басып тора:

– Әтисе, ни булды? Чирләмисеңдер бит, баядан бирле будильник белән сөйләшәсең?..

Хатынының ягымлы тавышы Фәнил Фаязны кабат өненә кайтарды. "Уф!" – диде ул тирләгән маңгаен мендәргә ышкып. "Аллага шөкер, акчасыз премия дигәннәре куркыныч төш кенә булган икән!"

"Тавык төшенә тары керә", – дия иде әбисе. Халык әйтсә, хак әйтә инде ул.

ЧуАр пресса

МИНЕМ ЙОРТ – МИНЕМ НЫГЫТМА

Петрозаводскида йорт төзүчеләргә йөкләмә биргәннәр – аварияле йортны сүтәргә. Адресны бутап, алар кешеләр яши торган яхшы йортны җимергәннәр. Аларны хәттә документта ике этажлы йорт дип язылу да уйландырмаган. Бер этажлы йортны утынга ишеп атканнар.

НЮ!

Кытайда яңа төр кредит бирә башлаганнар – студент кызларга фотоларын залогка калдырып. Кызлар фотода анадан тума чишенеп, паспортларын кулларына тотып төшкән булырга тиеш. Договорда кредитны вакытында түләмәсә, яшь чибәркәйнең фотосы социаль челтәргә йә әти-әнисенә элəгү мөмкинлеге язылган.

КЕМ “МЯУ” ДИГӘН?

Германиядән АКШка оча торган самолётта бортпроводниклар бер пассажирның салонга песи алып керүен сизеп алганнар. Экипаж членнары хайванны тотып алып бәдрәфкә япканнар. Ачуы чыккан песи хуҗасы үзен террористка дип белдергән, һәм, аңа дурт аяклы дустын кайтармасалар, самолётны шартлатачагын игълан иткән. Самолётның кичектергесез җиргә утыруы – АКШның һава истребительләре, ә террористканы самолёттан төшерү полиция ярдәмендә уздырыла.

УЕН!

Финляндиядә инде 20 ел күзалланган гитарада уйнау буенча Дөнья чемпионаты уздырылган. Соңгы конкурста Россиядән Кирилл Блюменкранц җиңгән. Шундый футбол ярышлары булмавы кызганыч. Безнекеләр анда беренчелекне алыр иде!

АТНЫ ГЫНА ТУКТАТМЫЙ

80 нче еллар ахырында мәктәп укучылары белән кызыклы хәл булган. Бер төркем балаларны Мәскәү астындагы Троицкидан тәҗрибә уртаклашу буенча Американың кечкенә бер шәһәренә җибәргәннәр. Андагы мәктәптә морпехларның укучыларга корал сүтәргә өйрәнү дәресенә эләккәннәр. Алар Калашников автоматын да сүткәннәр, тик җыя гына алмаганнар. Шунда 14 яшьлек укучы кыз чыккан һәм, бөтенесен шаккаттырып, автоматны җыйган.



Валерий ТАРАСЕНКО



Александр СЕРГЕЕВ



Николай ВОРОНЦОВ



ТУП ТИРӘЛИ

• • •


Безнең илдәге миллионлаган кешеләр футбол уйный белми, бары тик җыелма команда уенчылары гына аны зур акчага уйный.




Василий АЛЕКСАНДРОВ



Игорь КИЙКО




Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО






Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр


Тадеуш КАДЛЕЦ (Польша)



Уильям ФИШЕР (Англия)




Дэн Тираро (АКШ)




Мирослав БАРТАК (Чехия)



Генри БЮТНЕР (Германия)




Иржи КОТКА (Словакия)


Никола ЛАСТЕЦ (Чехия)

Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Армиядән оста качып йөрүчеләрне, әгәр дә мәгәр сугыш башланса, фронтка озатачаклар. Тәҗрибәләре буенча, алар партизаннар һәм подпольщиклар булачак.

• • •

Әби табибка килә:

— Нәрсәгә зарланасыз? Нәрсә борчый? — дип сорый табиб.

— Әй улым, аякларым да йөрми, кулларым сызлый, билемне бөгә алмыйм, башым чатный.

— Нәрсә дип әйтим соң? Диагнозың: “Дөмбәсләнгән әби” килеп чыга.

• • •

— Без хатын белән төнге клубта очраштык...

— Ой, нинди романтично!

— Әйе, менә, сиңа романтично! Мин бит аны өйдә балалар белән утыра дип уйладым.

• • •

Хөкемдар:

— Каян килгән ул сезгә йөз миллионлык шундый затлы бакча? Сезнең кебек түрәләрнең хезмәт хакы 50 мең генә бит...

Кулга алынучы:

— Аны минем җир кишәрлегемне карап йөргәндә ташлап киткәннәр...

• • •

Сез шуны беләсез микән, Гиппократ антының яңа редакциясенә менә мондый сүзләр өстәгәннәр: “Медицина полисы яки хезмәт күрсәткән өчен түләү квитанциясе булган очракта гына...”

• • •

Кайвакытта үзеңне комиссионка директоры итеп хис итәсең. Бөтенесе ерунда ташыйлар, чепуха белән шөгыльләнәләр.



Алексей ДОБРЫНИН

МӘХӘББӘТ ИСЕ

Коридорда гашыйк булган алар...
Таш подъездның «аулак» өнендә
Шәүләләре уйный пыялада:
Сөешәләр тәрәз төбендә.

Карап уздым моңа мин елмаеп,
Истәлекләр ташып күңлемдә.
Бар иде бит агач утыргычта
Яратышкан чагым минем дә...

Хәзер өйдә әллә ничә бүлмә –
Нинди мәйдан гашыйк тилегә!
Җылы мендәр-түшәк...
Ләкин анда
Мәхәббәтнең юк шул исе дә...

Ринат АБЗАЛОВ тәрҗемәсе

Нигә чәчсез?

Виталий ПОДВИЦКИЙ

Виктор БОГОРАД

ТАБЫШМАК БИЛ АЛЫШМАК

1. Салкын тигәндә нишләп сөт эчәргә кирәк?
2. Нигә без футбол буенча Дөнья чемпионатын 2018 елда Рәсәйдә үткәрү өчен бик нык тырыштык?
3. Иртән ярты сәгатькә озаграк йоклар өчен нәрсә булыша?
4. Эштә дәрәҗәлерәк урынга күтәрелү өчен нишләргә кирәк?
5. Нигә идеалист белән реалист котлет ашамыйлар?
6. Яшәү минимумын күтәрү өчен нәрсә кирәк?
7. Коллекторлардан ничек сакланырга мөмкин?

ЖАВАПЛАР

1. Анда антибиотиклар бик күп. 2. Чөнки безнең җыелма командага анда әләгү өчен бердәнбер ышаныч. 3. Кичтән юынып алырга, кырынырга, иртәнге ашыңны әзерләп куярга һәм киенгән килеш йокларга. 4. “Чыгырыңнан чыгып” эшләмәскә, югыйсә үзегезне алыштыргысыз кеше итеп күрсәтәчәксез, шуңа күрә сезне беркайчан да күтәрмәячәкләр! 5. Идеалист, бер гаепсез җәнлекне аның өчен үтергәннәр дип уйлый белә. Ә реалист, шушы котлетлар өчен бер генә җәнлек тә үлмәгән, ди. 6. Нәфес максимумнарын киметергә кирәк. 7. Кредит алган вакытта, максат шарты итеп, “Сайга” мылтыгы юнәлткәнлегеңне күрсәтергә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

ШИГЪРИ ДУЭЛЬ

Рашат Низами:
Узыйм дисәң әгәр җәннәткә —
Һич булышмас “блат”, әлбәттә…

Алмаз Хәмзин:
Кермим дисәң әгәр тәмугка —
Җый савап, батма гөнаһка!

Р. Н.:
Җирдә Чын һәм ялган булганда —
Мәңге көрәш барыр җиһанда!

А. Х.:
Хаклык өчен ялганласаң бер,
Шул ялганың бирер мең файда!

Р. Н.:
Такташ әйткән ике “мин” — миндә:
Үзем белән үзем сугышам.

А. Х.:
Аңа җайлы — ул икәү генә,
Ә мин өчәү инде тумыштан:
Үземне үзем кыйнау җитми,
Ил хәсрәте сыртка ябышкан.

Р. Н.:
Кискен әйтәм: ычкыныгыз юлдан,
Матурлыкка аяк чалучылар!

А. Х.:
Парламентта гырлап йоклаучылар,
Йоклаганга акча алучылар,
Бюджетка зур зыян салучылар,
Илне талап читкә качучылар!

Р. Н.:
Ике теләк кушылдымы –
Йөрәкләр күккә менә!

А. Х.:
Нидер теләп кенә, юкка,
Ир йөрәге күккә менмәс —
Син, Шагыйрь, менсәң генә!..

Р. Н.:
Ышанса кеше үзенең көченә –
Туры карый хәтта кеше күзенә!

А. Х.:
Ышанмаса да шулай итә бит ул —
Черки булып керә күзгә, түз генә.

Р. Н.:
Яшьлек ул уза, уза икән,
Картлыкка авышмасын җилкәң…

А. Х.:
Бар да уза, туза… Синең дә
Карттыр, кызыгып йөргән җиңгән?..



Валентин ДРУЖИНИН



Игорь КИЙКО



Николай КАПУСТА



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

№ 13 2016

Журнал айга бер тапкыр
рус һәм татар телләрендә чыга.

**«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры,
баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ**

Баш редактор урынбасары: Ринат АБЗАЛОВ
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
Александр АЛЕШИН
Үсеш бүлеге мөдире:
Павел СТАРОВЕРОВ
Җаваплы секретарь: Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА
Бүлек редакторлары:
Людмила САФИУЛЛИНА
Артём СУББОТКИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Алмаз ХӘМЗИН
Гузель СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Ләйсән ФӘЛАХОВА

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр
өлкәсендә күзәтчелек итүче
Федераль служба (Роскомнадзор)
идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789 18 май 2015 ел
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

**Редакция материалларны
авторларның ризалыгыннан башка
редакцияләү-төзәтү хокукына ия.**




татмедиа

Белешмәләр өчен
телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

16+

**Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2,
ТР, Казан, 420066**



Илдар НӘФИЕВ




Сергей ТЮНИН



Вячеслав ШИЛОВ

Уйна да, уйла да!

ЧАЯНВОРД



КОМПОЗИТОР РӘШИТ
ШАГЫЙРЬ ... ЕРИКӘЙ
ЯКЫН ДУС
ТАТАРСТАН ТЕЛЕВИДЕНИЕСЕ ДИКТОРЫ ... САКАЕВА
"...ЖИЛКӘН" (М. НОГМАН)
САМОЛЕТ
АКРИЛ БУЯВЫ
"ЯШЬ ... ЛАР СИН КАЛДЫРГАН ЭЗЛӘРНЕ ЖЫРЛЫЙЛАР" (И. ЮЗЕЕВ)
ШАГЫЙРЬ ... СӨНДЕКЛЕ
ЧУАР ПОПУГАЙ
ДИНИ ЙОЛА
"БЕЗНЕ КЕШЕ ИТКӘН — ..."
ФИКЕРЛӘР КӨРӘШЕ
"...(-1) ТУКМИ ИКМӘК УСМИ"
ХАЛЫК ЖЫРЫ
"АНДЫЙ ... ГЫНА КЫЗЫНДА ДА БУЛА"
(-1)... ДӘ БҮЛӘК, ДӨЯ ДӘ БҮЛӘК
"... ТОРА, ГАСКӘР КЕБИ ЧЫРШЫ-НАРАТ"
"АГЫЙДЕЛНЕҢ БУЙЛАРЫН ... КИЕП БУЙЛАМА"
РЕВОЛЮЦИОНЕР СУНЬ ЯТ-... (КЫТАЙ)
"ДАҺИ ЮЛБАШЧЫБЫЗ"
"КҮКТӘ МОҢЛЫ ЖЫР КАЛДЫРЫП ... КАЗЛАР ЧЫЛБЫРЫ" (А. ГАЛИМОВ)
ИТАР-... АГЕНТЛЫГЫ
"... БЕЛӘН СУ ТАШЫП БУЛМЫЙ"
БЕР ... ДАН БОТКА ПЕШМИ
ГАЛСТУГЫҢНЫ ...!
... МИМЕШ
КИЕЗ ...(-1)
БАШНЫҢ ИҢ КИРӘКЛЕ ӨЛЕШЕ
НОТА
"НИ СӨЙЛИ ..." (С. ХӘКИМ)
"... СУЛАР ГЕЛ ШУЛАЙ"
АФРИКАДАГЫ ДӘҮЛӘТ
"...ЖЕН-...ЛӘР БАР ДИЛӘР" (ТУКАЙ)
ХӘНЖӘРНЕҢ "ОЯСЫ"
МУЗЫКА ИНСТРУМЕНТЫ
КӨЧЛЕ, КАТЫ
"(-1)... ИКӘН КҮРӘСЕЛӘР"
"... КАНАТЫ АТ БУЛА"
"КАРА..." Г. ЗӘЙНАШЕВА
ДӨРЕС, ТӨГӘЛ (-1)
"... ПӘКЕ САПЛАРЫ"
ЕРТКЫЧ КОШ
КОМПОЗИТОР ... ВӘЛИУЛЛИН

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике жыр исемен укыгыз.
Журналыбызның 11 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«СИНЕ СӨЙДЕМ, ГҮЗӘЛЕМ», «ОНЫТМА».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Х. ӘХМӘТОВ (Кама Тамагы р-ны, Уразлино ав.),
Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Уразлино авылыннан
Халит ӘХМӘТОВ!

Отто ХОЙЗИНГЕР (Хорватия)



Отто ХОЙЗИНГЕР – немец токымыннан булган танылган Хорват карикатурачысы. Аның мәгънәле, үткен карикатуралары бөтен дөнья басмаларында таралган. «Чаян» битләрендә – аның вернисажы.





